Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты
карары

25 март 2020 ел № 428

Халыкара хезмәт ияләренең
теләктәшлек көненә багышланган
61 нче җиңел атлетика эстафетасын
оештыру һәм үткәрү турында

Җиңел атлетиканы үстерү һәм Әлмәт муниципаль районы халкын физик культура һәм спорт белән массакүләм шөгыльләнүгә җәлеп итү максатларында


БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Халыкара хезмәт ияләренең теләктәшлек көненә багышланган 61 нче җиңел атлетика эстафетасын үткәрергә.
2. Россия Эчке эшләр министрлыгының Әлмәт районы буенча бүлегенә (Багауов А.И.) 2020 елның 1 маенда Әлмәт шәһәрендә урамнарны ябуны әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә маршрутлар буенча 10:00 сәгатьтән 13:30 сәгатькә кадәр чорда тәкъдим итәргә.
3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү бүлегенә (Зарипова Л.Н.) хезмәт ияләренең Халыкара теләктәшлек көненә багышланган 61 нче җиңел атлетика эстафетасы турында халыкка хәбәр итәргә.
4. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.
5. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С. В. Лаптевага йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе М.Н. Гирфанов

Әлмәт муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның «25» март № 428
карары белән расланган
1 нче кушымта

2020 елның 1 маенда җиңел атлетика эстафетасы схемасы



2020 елның 1 маенда җиңел атлетика эстафетасы узган вакытта Ленин урамына чыгуларны ябу

Төзүчеләр проспектындагы боҗрадан Ленин урамына кадәр;
Ленин урамына «Нефтьче» мәдәният йорты ягыннан чыгу;
Сбербанк ягыннан Ленин урамына чыгу;
Ленин урамы чатыннан Мәрҗани урамына кадәр;
Ленин урамына «Татнефть» ГАҖннән чыгу;
«Пятерочка» мини-маркет ишегалдыннан Ленин урамына чыгу;
Ленин урамы чатыннан Заслонов урамына кадәр;
Ленин урамында «Дом Света» кибете ишегалдыннан чыгу;
Ленин урамына Главпочтамт бинасының ишегалдыннан чыгу;
Ленин урамы чатыннан Җәлил урамына кадәр..

Район
Башкарма комитеты җитәкчесенең
социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С.В. Лаптева